**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Яңа Үргәагар авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Новоургагарского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422870, ТР, Әлки районы,
Иске Үргәагар авылы, Г.Тукай урамы,
4 йорт, тел/факс 8 (84346) 73776

422870, РТ, Алькеевский район,
с.Старые Ургагары, ул.Г.Тукая, д.4
тел/факс 8 (84346) 73776

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Иске Үргәагар ав.** **КАРАР**

**2025 елның» 09 " июненнән** **№ 10**

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Яңа Үргәагар авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Яңа Үргәагар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күпләп җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Иске Үргәагар авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә, Г. Тукай ур. буйлап 200 метр ераклыкта;
- Яңа Үргәагар авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, Кояш урамыннан 200 метр ераклыкта;
- Яңа Үргәагар авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә 300 метр ераклыкта М.Җәлил урамы буйлап.

Бу территорияләрдә «Йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Яңа Үргәагар авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ә. Ә. Рәхимҗанов